Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Шәһәр тибындагы
Аксубай поселогы
Башкарма комитеты
423060, Аксубай штп,
Советлар урамы, 2 нче йорт
т.2-73-62

Исполнительный комитет
поселка городского типа Аксубаево
Аксубаевского муниципального района
Республики Татарстан
423060, пгт Аксубаево,
ул.Советская, д.2
т. 2-73-62

КАРАР

10.12.2021 ел № 16

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Аксубай шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районы Аксубай шәһәр тибындагы поселогында адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 29.07.2021, №10 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 27.07.2010, № 210-ФЗ Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районы Аксубай шәһәр тибындагы поселогында адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 29.07.2021, № 10 номерлы карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 пунктының 2-10 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Регламентта дәүләт адреслы реестрын алып бару һәм федераль мәгълүмати адреслы системаны эксплуатацияләүгә бәйле кулланыла торган төшенчәләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Федераль мәгълүмати адреслы система һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында " 28.12.2013, № 443-ФЗ Федераль законы, «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару Кагыйдәләрен раслау турында» 19.11.2014, № 1221 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән тәгәл яраштырып кулланыла.»;

1.2. 1.5 пунктның 11-17 абзацларын 3-9 абзацлар дип санарга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм түбәндәге адрес буенча: http:/pravo. tatarstan. ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми

порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында түбәндәге адрес буенча: http://aksubayevo.tatarstan.ru Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе
Аксубай шәһәр тибындагы поселогы А.М. Бакиров